Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № XXXIV-1**

Котлы Бөкәш авылы 2017 елның 27 сентябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты “в” пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Котлы Бөкәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 21сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” 26 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 сентябрендәге “Референдум үткәрү инициативасы турында” XXXIII номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

“Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан гайре, тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәрбер кешенең 2017 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

- авыл жирлеклэренэ караган зиратларга контейнерлар урнаштыру;
- кышкы юлларны кардан чистарту;
- Котлы Бөкәш авылы урамнарына вак таш җәю;
- урам утларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;

- Котлы Бөкәш зиратының үзәк капкасын урнаштыру;
- торак пунктлардагы зиратлар территорияләрен юридик документлаштыру

Сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы Г.Г. Нәҗипов